## Соңгы әманәт

Җәйге айлы төн. Куе шәмәхә төскә төренгән күк йөзендә, бар җиһанга сихри төсмер өстәп, якты йолдызлар җемелдәшә. Без, авылдашым Әхәт абзый белән икәүдән-икәү генә, авыл уртасындагы камышлы күл буенда балык чистартып утырабыз.

Каршыбызда, тирә-юньгә бихисап чаткылар чәчрәтеп, чытырдый-чытырдый, учак яна. Түгәрәк күлне урталай бүлеп, озын ак тасмадай сузылган ай нурлары җем-җем ялтырый, көмеш тәңкәле балыклар чулт-чулт килеп, сикерешеп уйный. Этләрнең йокы аралаш вакыт-вакыт иренеп кенә өреп куйганнары ишетелгәли.

Ерганактагы таллар арасыннан әрсез бакалар аваз биргәли. Аяк астындагы үлән эчендә тынгысыз чикерткәләр, табигатьнең хозурлыгын үзләренчә мактарга теләгәндәй, ниндидер көй чыгармакчы булып азаплана.

Учак тирәсен чолгап алган серле тынлыкны бозарга кыймыйча, сүзсез генә утырабыз.

Ниһаять, балыкларны әйбәтләп юып җиз казанга салгач, мин учак янәшәсендәге брезент плащка барып яттым. Әхәт абзый исә, бәләкәй казан тирәсендә мәш килеп, балык шулпасы әзерләргә кереште. Аның өчен моңардан да ләззәтле, рәхәт эш юктыр, мөгаен. Бу минутларда ул һичкемне күрми дә, ишетми дә. Аның бөтен игътибары учак өстендә быгыр-быгыр кайнаган корымлы казанга юнәлгән. Ут янында сихерле сүзләр мыгырдап, биеп йөргән шаман сыман, авыз эченнән ниндидер догалар укыштырып, дөньясын онытып, аш пешерү белән мәшгуль. Аның хәрәкәтләре җитез, куллары уйнап тора. Уха пешерү — аның үлеп яраткан шөгыле. Балык шулпасын аннан да оста әзерләүче кешене көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Ашы тел-

не йотарлык була, авызга кабуга, май сыман эри дә китә. Могҗиза инде менә! Гомер буе аш-су тирәсендә генә әвәрә килеп яшәгән икән бу, диярсең. Юкса трактордан төшкәне дә юк бит инде. Көне-төне басудан кайтып керми ул. Күп вакыт шунда кунып та кала дип ишеткәнем бар.

Мин, эше беткән, ваемсыз кеше кебек, кырын ята төшеп, игътибар белән Әхәт абзыйны күзәтәм.

Беренче карашка, шактый гомер кичергән авыл картын хәтерләтә ул. Ә бит үзе чагыштырмача яшь — яңа гына 55 ен тутырган. Бәләкәй гәүдәле, киң җилкәле, камыт аяклы, көрәк куллы ир-егет. Болай бер дә ачык йөзле, ягымлы кешегә охшамаган. Киң маңгаен буйдан-буйга сызып узган тирән эзләр, калын кашлары аны кырыс холыклы, усал кыяфәтле итеп күрсәтә. Аны якыннан белмәгәннәр башта нәкъ менә шундый төксе кеше дип уйлыйлар да. Бары тик соңрак, һәрчак көлеп торган яшькелт күзләрен, иреннәре читендә әледән-әле пәйда булган хәйләкәр, шаян елмаю билгеләрен күргәч кенә, ялгышуларына төшенә башлыйлар. Шулай булмый ни, Әхәт абзыйдан да җан җылымлы, шаян-шук кешене очратып карагыз әле.

Әгәр ул сөйли башласа, тыныч кына утырырмын димә: тыңлаганда көлә-көлә эчләр катып бетә, күздән берөзлексез яшь ага. Теленә шайтан төкергән, каһәрнең. Тикмәгә генә аяклы кәмит дип атамаганнардыр инде аны. Үз башыннан үткән кызыклы вакыйгаларны атказанган артистлардан да болайрак, оста итеп сурәтли белә.

Менә хәзер дә эшен тизрәк төгәлләп, мәзәк сөйли башлавын түземсезлек белән көтеп, кыбырсып ятам.

Әхәт абзый, уйларымны сизгәндәй, ниндидер бер җитезлек белән туралган бәрәңгеләрне бәләкәй казанга салгач, кулларын коры чүпрәккә сөртә-сөртә, агач түмгәгенә барып утырды. Бер чытырдап янган учакка, бертын күлгә карап, үзалдына нидер уйланып торды. Аннары, кисәк кенә минем якка борылып, моңсу тавыш белән әйтеп куйды:

— Сугыш вакытында безнең авылдагы бер яман хәл турында ишеткәнең бар идеме?

Ни дияргә дә белмичә, бер мәлгә югалып калдым. Әхәт абзый, яшькелт күзләрен кыса төшеп, минем җавабымны көтә. Миңа ул чордагы күпләгән вакыйгаларның барысын да кабат искә төшереп, барлап чыгу ансат булмады. Ниһаять, кайчандыр авылыбыздан 6—7 чакрымдагы тимер юл буенда кемнеңдер үле гәүдәсе табылуы турында бала чагымда әтидән ишеткәннәрем хәтергә килде. Шуны

Әхәт абзыйга әйттем. Ләкин моның белән генә чикләнәсе килмәде, ахры, тагын сорау бирде:

— Ә син аның нилектән харап булганын беләсеңме соң?

Менә монысы инде миңа бөтенләй караңгы иде. Балачакта бит андый күңелсез хәлләргә артык әһәмият бирмисең; олы-карадан ишеткәннәр бер колактан керә, икенчесеннән чыга дигәндәй, тизрәк онытасың. Дөрес, бераз үсә төшкәч, ул фаҗига турында кайбер агайлардан сөйләтергә омтылып караган идем каравын. Тик барысы да бушка булды: әңгәмәдәшләр, ул җан өшеткеч вакыйга хакында авыз ачуга, әллә нинди сылтаулар табып, янымнан җәтрәк китәргә ашыктылар. Шуннан бирле бу ниятемнән баш тарттым, бүтән беркемнән дә ул хәлне белешергә талпынмадым. Сөйләмиләр икән, димәк, ниндидер бер сәбәбе бардыр дигән нәтиҗәгә килдем дә тындым.

Шулай да ул хәлне ачыклау теләге озак вакыт күңелдә йөрде. Фәкать авылдан Казанга укырга киткәч кенә исемнән чыкты, хәтердән җуелды.

Инде менә бүген, шактый гомер узгач, тормыш буразналары катламы астында томаланып калган әлеге вакыйга бер дә көтмәгәндә кабат өскә калкып чыгар дип кем уйлаган? Гадәттән тыш ул хәл турында моңа кадәр анык кына берни дә белмәвем өчен ирексездән уңайсыз булып китте. Күпме генә теләсәм дә, Әхәт абзыйга бу хакта авыз тутырып нидер әйтергә гаҗиз идем.

— Берни дә хәтердә калмаган шул, — дидем мин, башымны аска иеп. Бераздан аклангандай әйтеп куйдым: — Ул турыда авылда да белмиләр ич хәзер.

Әхәт абзый, минем сүземне килештермичәме, башын чайкап куйды. Аның күз карашында, җыерчыклы йөзендә шелтә катыш рәнҗү чалымнары күреп гаҗәпкә калдым.

Ни булган аңа? Нигә шулай хәсрәтләнә ул? Әллә кайчан булып узган фаҗигане бүген ни өчен искә төшереп азаплана? Тормыш тормыш инде ул: кеше туа, яши, үлә. Дөньясы шулай яратылган. Кем әйтмешли, үлгән артыннан үлеп булмый бит дигән уйлар баштан узды.

Әхәт абзый шактый вакыт дәшми генә утырды. Кулындагы таяк белән учактагы күмерләрне болгата-болгата, үпкәләгәндәй, миңа карамыйча гына әйтеп куйды:

— Шулаен шулай. Син хаклы, амам*. Аны авылда беркем дә искә төшерергә яратмый. Ни өчен дисәң, күпләрнең вөҗданнары саф түгел. Ә бит аның үлеменә без барыбыз да гаепле. Мин, бәлкем, күбрәк тәдер әле.

Аның соңгы сүзләре, бер яктан, минем кызыксынуымны тагын да көчәйтсә, икенче яктан, күңелдә нindidер шик-шөбһә уятты. Әхәт абзый тикмәгә генә шул рәвешле сүз башламагандыр, бик тирән яшеренгән берәр серне белә бугай ул. Үзе дә бит әнә, гаеп миндә дә бар, дип әйтеп тора. Кыскасы, форсаттан файдаланып калырга кирәк. Мин, бөтен кыюлыгымны җыеп:

— Юкка үзеңне чыбыркылап утырасың. Синең урында булсам, барысын да уртага салып сөйләр идем. Әйдә, тарсынып торма, тот та чиш сереңне. Бераз күңелең бушаныр... — дидем.

Әхәт абзый сискәнеп китте дә миңа сынаулы карашын төбәде.

— Шулай дисеңме? Сөйләргә була анысы. Тик тыңлап бетерергә түземлегең җитәрме соң?

— Төн озын. Ашыгыр җирем юк. Әйдә, ялындырма, бер башлагач, ярты юлда туктап калма инде.

Әхәт абзый бераз икеләнеп торды. Аннары, кулын селтәп:

— Йә, ярар, алайса. Сиңа сөйләмичә котылып булмас, ахры. Тик белеп тор: бу хакта әле беркемгә дә авыз ачканым булмады... Әйдә, ухадан авыз итеп алыйк та.

Әхәт абзый казанны учак өстеннән чирәмгә алып куйды да савытларга хуш исле балык шулпасы бүлде. Мин, биштәрдән үзем белән алып килгән «акбаш»ны тартып чыгарып, «зәһәр эчемлек»не калай кружкаларга агыздым. Әхәт абзыйның, күңеле булып, күзләрендә шаян, дәртле чаткылар кабынды.

— Син мине гөнаһлы итәсең бит болай... Бу «шайтан малае» белән күптән дуслыкны өзгән идем. Синең хөрмәткә тотып куйсам гына инде, — дип сөйләнә-сөйләнә, аракы салынган савытны кулына алды.

Балык шулпасыннан авыз иттек. Тәмәке кабызып җибәрдем. Әхәт абзыйның шактый еллар тартмаганын белгәнгә күрә, аны кыстап тормадым. Әмма ул, гаҗәпкә каршы, үзе сорап алды:

— Кая, бир әле пупирусыңны. Бәлки, йөрәкнең сызлавы басылыр, — диде дә бер-ике суыргач атып бәрде: — Бармый. Тартасы тартылган, эчәсе эчелгән, күрәсең.

Бераз сүзсез генә, уйларына бирелеп утыргач, Әхәт абзый үзенең хикәятен башлады:

— Үземне белгәннән бирле, безнең Асаба авылы кешеләрен тирә-яктагылар «Ухарь-купич» дип үртәп йөрделәр. Шул кушамат аркасында күпме иза чиккәнемне бел-

сәң иде, туганым. Аны бер сүз белән генә аңлатырлык түгел. Ул вакытлардан бирле никадәр вакыт узды, әмма дә ләкин күрше Андреевкадагы салам чәчле, кызыл йөзле малайларның «Татарин-барин», «Ухарь-упич» дип такмаклап, арттан үчекләп чабулары әле дә истән чыкмый. Ярый әле, мыскыллап кына калсалар, авылларыннан узганда, таш атып калырга да күп сорап тормый иде ул чукынмышлар. Ай, ул чакта баштан кичкәннәрне сөйләсәң, кеше ышанмас, валлаһи менә...

Син хәтерләмисеңдер инде андый хәлләрне. Сезгә эләкмәде ул үртәүләр. Сез үскәндә, заманалар башка иде. Ул кушамат тагучыларның күбесе инде гүр иясе булды яки каядыр читкә китте. «Купич» итенгәләп үртәп телгә алулар бетте. Әйтсәләр дә, кызык өчен генә, яшьлек елларын сагынып искә төшергәндә генә инде.

Ләкин мин онытмадым. Ничек истән чыксын ди ул! Соң, туганым, үзең уйлап кара: аякта тишек галуш, өстә әни мәрхүм сырып биргән ертык куфайка*, башта кәлҗемә сымак ямьшәйгән фуражка кәмәше. Ыштанны әйткән дә юк — төрле төстәге чүпрәк-чапрак ямаудан аллы-гөлле булып тора. Чистый чуваш катыннары итәге инде. Кабам дисәң, үдә* бер кабым әпәй* валчыгы да таба алмассың. Кычыткан шулпасы эләксә шөкер итәрсең. Ызбаны ызба димәсәң хәтере калыр, яртылаш җиргә сеңгән землянка инде. Ә монда, җитмәсә, тешләрен ыржайтып, «Купич» дип, шаркылдап торалар! Йә, нинди купич инде мин? Ничек түзмәк кирәк бу хурлыкка? Ләкин, нишлисең, түзәргә туры килде.

Син, мужыт, эчтән генә мин карт җүләрдән көлеп утырасыңдыр әле. Булган, беткән бит инде, дисеңдер. Бәлки, шулайдыр да. Тукай бабай әйтмешли, былтыр кысканга, быел кычкырмыйлар. Прусты, сөйли башлагач, уйламаганнитмәгәндә искә килеп төште бит, шайтан алгыры. Нахакны кечкенәдән күтәрә алмыйм, хет үтер менә. Гаделлек өчен җанымны-тәнемне бирердәй булам...

Әхәт абзый кисәк кенә сөйләүдән туктап калды. Калтыраган бармаклары белән калай кружкага үрелде. Бер-ике йотым уртлагач, кулына янә чыбык кисәге алып, сүнеп барган учактагы утлы күмерләрне болгаткалады. Бераздан, читкә борыла төшеп кеһ-кеһ ютәлләгәннән соң, тәмам тынычланып, сөйләвен дәвам итте:

— Шулай да ул кушамат безгә яңылыш* тагылган дип тә кистереп әйтергә җыенмыйм. Бабайлар, үзеңдәгене күр-